ГЛАВА
МАЛОМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КЕЧЕ МӘМИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.11.2025 ел. Кече Мәми ав. № 4

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кайбыч муниципаль районының Малалла торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. 2025 елның 26 ноябрендә 10 сәгатькә Малалла ав., Коммуны урамы, №12 нче йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авылы җирлегендә ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2026 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлеге Малалла торак пункты территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнардан һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;
- торак пункт территориясен төзекләндерү?»

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, акчаны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ»?

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://mmemin-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Кече Мәми авыл җирлеге Башлыгы Е.Н.Алексеева